«(Ий, Пәйгамбәр!) Син үгетлә, чөнки мөэминнәр өчен үгеттә файда бар»

**Китап сүзе**

# Кирелек булган җирдә акыл юклыгы расланадыр

Барча олуг мактауларыбыз, шөкераналарыбыз: «Ий Мөхәммәт гәйләйһиссәләм, Без сиңа Коръән иңдердек, кешеләр өчен җентекләп иңдерелгән шәригать хөкемнәрен өйрәтмәклегең өчен, шаять ишетеп, фикерләп карарлар вә аңлап кабул итәрләр», - дип әйткән, бөтен галәмнәрне бар итеп тәрбиялəп торучы Аллаһы Сөбханә вә Хак Тәгаләгә булса иде.

«Сезнең иң яхшыларыгыз - Коръәнне өйрәнгән һәм башкаларга өйрәтүче», - дигән иң изге Пәйгамбәрләрдән булган Мөхәммәт (с.г.в.)гә Аллаһының хөердогасы вә сәламе ирешеп торса иде.

Әгәр без үзебезнең тормышка күз салсак, күрәбез: кешеләр күп вакытта үзләренең күнеккән гадәтләре буенча яшиләр.

**Гадәт - еш кабатланган сүзләр һәм эшләр дисәк, ялгыш булмастыр.**

Шуңа күрә берәр нәрсә гадәткә керсен өчен күп кабатланырга һәм күңелгә иңәргә тиештер.

Гадәт дигәнебезнең, барлык нәрсәсенең ике ягы булган кебек, яхшысы һәм начары бардыр.

Яхшы гадәт шәригатькә туры булып, начар гадәт шәригатькә киредер.

Кешелек дөньясына карасак, *«кирелек кайчан килеп чыккан?»*- дигән сорауга Коръән-Кәрим җавап бирәдер:

«Хөрмәт йөзеннән Адәмгә сәҗдә кылыгыз», дип әйткән вакытыбызда, алар (фәрештәләр) сәҗдә кылдылар, мәгәр Иблис сәҗдә кылмады, киреләнде һәм кәферләрдән булды», - ди Аллаһы Тәгалә. Бу аятьтән күрәбез ки, кирелек - шайтанга һәм аңа иярүчеләргә хас сыйфаттыр. Адәм балалары арасында иң беренче кире кеше Кабил иде. Атабыз Адәм шәригате буенча ул икенче корсактан булган Ләбүдәгә өйләнергә тиеш иде, киреләнде, үзе белән бер корсакта булган Әкълимәгә өйләнергә теләде, ә туганы Һабилгә Әкълимә тиеш иде. Корбан кылдылар, Һабилнеке кабул булды, Әкълимәнең Һабилгә тиешлеге расланды. Кабилнеке кабул булмады, Кабил нишләргә белмәде, шунда Иблис бер кара кош белән килде, кошны таш белән бәреп үтерде, Иблистән Кабил кеше үтерергә өйрәнде, Һабилне үтерде, кирелек кеше үтерүгә - зур гөнаһка китерде.

Еллар, гасырлар үтә торды, Адәм балалары кирелекләре сәбәпле, Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәрләрне аша иңдерелеп торган диннәрен боза тордылар, кайберләре үзләренең Пәйгамбәрләрен үтерделәр, кайберләре аларны тәрлечә мәсхәрәләделәр, рәнҗеттеләр һәм, нәтиҗә буларак, Аллаһы Тәгалә аларны җир йөзеннән юк итеп торды. Шулай итеп, кирелек зыяны үзләренә ирешеп торды.

Җир йөзендә Аллаһы дине юкка чыгу дәрәҗәсендә булганда, Ибраһим гәләйһиссәләм дога кылды:

"Ий, Раббыбыз! Бездән соң нәселебезгә үзләре арасыннан Пәйгамбәр күндер.

**Ул Пәйгамбәр өйрәтер аларга Синең китабыңны һәм Ислам диненең бөтен хөкемнәрен»,** - дип.

Ибраһим гәләйһиссәләм догасы бәрәкәтендә Мөхәммәт (с.г.в.) дөньяга килергә вакыт җитте һәм аңа 610 елда Пәйгамбәрлек иңде. Аның тормышының һәр мизгеле барлык халыкка билгеле иде һәм кыямәт көненә чаклы шулай булуында да шик юк иде.

Аның сыйфаты турылык, тыңлаучан, дөреслек булганга, әле аңа Пәйгамбәрлек килгәнче үк исеменә *«Ышанычлы»* дигән кушымта куелган иде, ягъни *Мөхәммәт Әмин* диелде.

Аллаһы Тәгалә: «Ий, Пәйгамбәр гәләйһиссәләм, Без сине Ислам шәригатен кешеләргә ирештергәнлегеңә шаһит итеп, сиңа ияреп, Коръән белән гамәл кылмаучы кире кешеләрне җәһәннәм газабы белән куркытучы итеп җибәрдек (33:45).

**Дәхи сине Аллаһының әмере буенча кешеләрне Аллаһыга иманга вә Ислам динен кабул итәргә өндәүче итеп, вә синең белән кешеләр туры юлны тапсыннар, сине белем яктылыгы белән җибәрдек (33:46)»,** - диде.

Ий, җәмәгать!

Ничек дип уйлыйсыз?

Мөхәммәт гәләйһиссәләмнең якын туганнары кавеме туры хикмәтле яхшылыкка өндәүче Аллаһы сүзен кабул иттеләрме?

Менә инде кешеләрнең кирелеге ни дәрәҗәдә кабәхәт, яман булуын Аллаһының илчесенә татырга туры килде. Моңарга Коръәннең 17нче сүрәсенең 89, 90, 91, аятьләре дәлил булып тора.

Шулай ук «Яки, үзең әйткәнчә, күкне кисәк-кисәк итеп, өстебезгә төшергәнеңчә,

яки Аллаһыны вә фәрештәләрне алдыбызга китереп бастырганыңдача,

яки синең алтыннан өең булганыңдача,

яки күккә менгәнеңчә,

күккә менсәң дә, ышанмыйбыз, аннан китап алып килеп безгә укытмасаң,

**шушы нәрсәләрне эшләмәсәң сиңа иман китермибез»,** - диделәр (17-92, 93).

Киреләнгән кавемнең бармак белән санарлыгы гына кире үгел иде, Ислам динен кабул итеп, аның хөкемнәре белән яши башладылар.

Купчелек шуның хәтле киреләнде, кирелекләре шул хәтле зур иде, иман китергән кешеләрне үтерделәр,

мәсхәрәләделәр,

хәтта Пәйгамбәр гәләйһиссәләмне үтерергә җыендылар.

Менә кирелек адәм баласын ни дәрәҗәдә хурлыкка, җинаятькә этәрә.

**Кирелек булган җирдә акыл юклыгы расланадыр.**

Кирелек - тәкәбберлекнең, надан-лыкның, ялкаулыкның тышкы күренешедер. Ничек намаз иманның тышкы күренеше булган кеби.

Пәйгамбәр (с.г.в.) әйтте:

«Кемдә тәкәбберлек тузан бөртеге хәтле күренсә,

аңа җәннәт хәрәмдер,

**наданлык кәферлеккә тиңдер, ялкаулык шайтан фабрика-сыдыр»,** - диде.

Кире кешеләр Коръән һәм сөннәтне ташлап, күп очракта мәҗүсиләрдән калган

яки динсезләр уйлап чыгарган гореф-гадәтләр белән яшиләрдер.

Аларның бәйрәмнәрен бәйрәм итәләрдер.

Кирелекнең бер сәбәбе, бәлки, «мин мөселман», дип әйтүчеләрнең дөрес итеп ашый-эчә белмәүләредер.

Мөхәммәт (с.г.в.):

«Ашар алдыннан бисмиллаһ әйтегез.

Уң кулыгыз белән ашагыз, эчегез.

Шайтан сул кулы белән ашый-эчә», - дип өммәтен шайтанга көч-куәт бирүдән тыйды.

Гомәр хәзрәт киреләрне камчы белән дөрес ашарга өйрәтте һәм сәхабәләр уң куллары булмаган очракта гына сулы белән ашадылар-эчтеләр.

Чөнки алар Аллаһы Тәгаләнең Коръәндәге: «... шайтанның шәреннән Аллаһыга сыгын... (41-36)»,

«Мин шайтанның вәсвәсәләреннән, аларның адәмнәрне адашуга кертүләреннән, Раббым, Сиңа сыенам!

Мин намаз яки Коръән укыганда минем янымнан булуларыннан Сиңа сыенам (23 - 97, 98)», - дигән фәрманын яхшы хәтерләгәннәр.

Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә:

**«Сезгә Пәйгамбәр (с.г.в.) - яхшы үрнәк»,** - ди. Шулай булгач, аның һичбер хөкеменә бу әһәмиятсез дип карау зур хата булыр. Нәрсәне үтәү хәзер мөмкин, шуны үти башларга тырышу тиештер.

Йә, Рабби, безне:

«Ишеттек, буйсындык», диючеләрдән кылсаң иде!

Кирелекләрдән азат кылсаң иде!

Безне: «Нәрсә булган аларга, ни сәбәпле батылдан хакны аеручы Коръәннән баш тарталар?

Алар Коръәннән вә аның вәгазьләреннән һәм хөкемнәреннән качалар, куркып өреккән ишәк кеби», - дигән аятьләрең астына кертмәсәң иде.

Әлхәмду лиллаһи Раббил гәләмин.

**Фарук ЗИННӘТУЛЛА.**

**Хатыннарыбыз**

# Ирләрнең өйдә утырулары, хатыннарның читләрдә йөрүләре - фәкыйрьлек китерә торган нәрсәдер

Кешеләрнең бәхет-сәгадәтләре — хатыннар кулындадыр.

Бер хатынның байлыгы — иренең мәхәббәтедер.

Ирләр тән булсалар, хатыннар — җандыр.

Адәмнең өендә алдан күрүчән вә тәрбияле бер хатын булмаса, аның хәле шикле булыр.

Бер хатын фәкать бер ирне генә бәхетле итәргә бурычлыдыр.

Хатыннарның иң хөрмәтлесе — иң канәгать булганыдыр.

Яхшы яшәү гүзәл холыклы хатыннан башка булмас.

Хатын — фәкыйрьлеккә каршы бер гаскәрдер.

Чиста хатынның пычрак хезмәтчесе булмас.

Ирләрнең өйдә утырулары, хатыннарның читләрдә йөрүләре — фәкыйрьлек китерә торган нәрсәләрдер.

Тәкәбберлек — һәркем өчен юкка чыгара торган бер гадәт булган кебек, хатыннар өчен тагын да артыграк юкка чыгара торган бер гадәттер.

Балаларын күреп, аналарның гыйлем вә тәрбиясен, пакьлек вә зирәклеген аңларсыз.

Гүзәллеге белән мактанучы хатын гүзәл түгел, бәлки, тәрбияле хатын — гүзәлдер.

Хатыннарның елмаеп көлүләре никадәр татлы булса, кычкырып көлүләре — шулкадәр татсыздыр.

Дөньяның бәхетсезләре — тәрбияле хатын белән тәрбияле баладан мәхрүм булган затлардыр.

**Ризаэтдин ФӘХРЕТДИН.**

## Уважаемые налогоплательщики!

Если вы сдаете налоговые декларации и расчеты в бумажном виде, советуем вам использовать формы нового поколения – машино-ориентированные бланки с двухмерным штрих-кодом (2-ШК).

Штриховое кодирование с использованием символики является наиболее эффективной, отработанной и доступной технологией автоматической идентификации информации с бумажных носителей.

Технология двухмерного штрих-кодирования не требует от пользователя никаких дополнительных технических знаний, специальных программ для формирования электронно-цифровой подписи и шифрования, доступа в сеть Интернет.

Для налогоплательщика использование форм на бланках с двухмерным штрих-кодом 2-ШК открывает существенные преимущества этого способа представления отчетности

**1) Высокая скорость обработки данных и раннее выявление возможных разногласий.** Двухмерный штрих-код позволяет считывать информацию специальным сканером, что в несколько раз ускоряет процесс ввода информации в карточки расчета с бюджетом налогоплательщика.

**2) Исключение ошибок инспекции.** Автоматизированный ввод данных исключает человеческий фактор, то есть устраняются ошибки налогового инспектора и осуществляется строгий учет каждого листа документа.

**3) Экономия времени налогоплательщика.** Сокращается время приема отчетности налоговым инспектором, так как декларации (расчеты) проверяются только визуально. Отсутствует необходимость проверки данных на возможные вирусы, не требуется предоставления магнитного носителя.

**4) Бесплатно.** От плательщиков не требуется дополнительных затрат – добавить в декларацию штрих-код позволяют обычные бухгалтерские и налоговые программы. Штрих-код идеально печатается как на лазерных, струйных, так и на матричных принтерах, и его одинаково хорошо считывает сканер.

**Программное обеспечение можно найти на сайтах Федеральной налоговой службы (www.nalog.ru ), Управления ФНС России по Самарской области (www.r63.nalog.ru ) в разделе «В помощь налогоплательщику», подраздел «Программные средства», на сайте ГНИВЦ ФНС России www.gnivc.ru , а также записать в компьютере общего пользования, установленном в операционном зале инспекции.**

## Балаларыгызга түбәндәге исемнәрне кушыгыз

Идрис
Салих
Исхак
Якуб
Әюб
Муса
Һарун
Сөләйман
Илйас
Юныс
Зәкәрия
Гайсә
Адил
Адилә
Азамат
Айдар
Айрат
Айсылу
Алсу
Асия
Бакир
Банат, Бәнат
Бану
Басыйр

* * *